# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 28 марты** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Александровка авыл җирлеге Яхшы-Каран торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылы торак пунктында 2024 елда үзара салым кертү турында» 17 ноябрь 2023 елнын 2нче номерлы карарына узгәрешләр кертү турында чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

« 1. Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (тышкы яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергияне саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү; Яхшы-Каран п. б.).

2. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш катламын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирование) Мифтахов урамындагы Яхшы Каран п.б.

3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемлеге белән истәлек тактасын урнаштыру, һәйкәлне ремонтлау, Яхши-Каран бистәсендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2. Әлеге карарны Александровка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин